КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 июль г.Казань № 737

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 22 июль, 515 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә булышлык күрсәтү, эшмәкәрлек мәнфәгатьләрен яклау һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген популярлаштыру максатларында коммерциячел булмаган оешмаларга инвестицион климатны яхшыртуга, инвестицияләр җәлеп итүгә һәм халыкара элемтәләрне үстерүгә юнәлдерелгән форумнар, күргәзмәләр, конгресслар, конференцияләр, җыеннар, семинарлар, стратегик сессияләр, «түгәрәк өстәлләр», шулай ук комиссия утырышларында катнашу, оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә булышлык күрсәтү, эшмәкәрлек мәнфәгатьләрен яклау һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген популярлаштыру максатларында коммерциячел булмаган оешмаларга инвестицион климатны яхшыртуга, инвестицияләр җәлеп итүгә һәм халыкара элемтәләрне үстерүгә юнәлдерелгән форумнар, күргәзмәләр, конгресслар, конференцияләр, җыеннар, семинарлар, стратегик сессияләр, «түгәрәк өстәлләр», шулай ук комиссия утырышларында катнашу, оештыру һәм

үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 22 июль, 515 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 10 сентябрь, 764 нче; 2019 ел, 28 август, 722 нче; 2020 ел, 28 август, 754 нче; 2021 ел, 31 май, 415 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә булышлык күрсәтү, эшмәкәрлек мәнфәгатьләрен яклау һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген популярлаштыру максатларында коммерциячел булмаган оешмаларга инвестицион климатны яхшыртуга, инвестицияләр җәлеп итүгә һәм халыкара элемтәләрне үстерүгә юнәлдерелгән форумнар, күргәзмәләр, конгресслар, конференцияләр, җыеннар, семинарлар, стратегик сессияләр, «түгәрәк өстәлләр», шулай ук комиссия утырышларында катнашу, оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.7 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында, шулай ук тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы законы проектын формалаштырганда» сүзләрен өстәргә;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Заявкалар Министрлык тарафыннан кабул ителә.

Министрлык бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында, заявкалар кабул ителә башланган көнгә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 5.4 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә коммерциягә карамаган оешмаларга карата таләпләрне һәм коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 3.1 – 3.4 пунктлары нигезендә оешмалар заявкалары формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

бу Тәртипнең 4.2 пункты нигезендә заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 4.2 – 4.6 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

коммерциягә карамаган оешмаларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләрен аңлату тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогын;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын;

бу Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә коммерциягә карамаган оешмаларны сайлап алу критерийларын;

5.1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия күләме, каплау максаты белән субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлеше, өстәмә хисаплылык бирү сроклары һәм формалары (кирәк булганда), коммерциягә карамаган оешманың үзенә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү өлешендә), дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;»;

17 пунктның икенче абзацында «нәтиҗәләренә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга;

5.6 пунктта:

икенче абзацта «шартларын» сүзеннән соң «һәм тәртибен» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта татар текстында «нәтиҗәләренә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга;

5.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Министрлык коммерциягә карамаган оешманың субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ и $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

«Министрлык, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү фактын чагылдыра торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүгә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча мониторинг үткәрә.»;

5.9 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Тәртипнең 2.1 пунктындагы өченче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы егерме сигезенче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин